КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 21 март г.Казань № 163

2025 елда «Физика-математика алгарышы» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2025 елда «Физика-математика алгарышы» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин